| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘХМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

23 октябрь 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2023 елның 16 ноябрендә сәгать 13 сәгать 00 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 1-61нче йортларда яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2023 елның 16 ноябрендә сәгать 14 сәгать 00 минутка Кооператив урамы, 78 адресы буенча урнашкан кибет бинасы янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегенең Чишмә поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Кооператив урамы 2-76нчы йортларда, Шоссе урамында яшәүчеләр өчен гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2024 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Чишмә поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан, 85 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту;

- Чишмә бистәсендә урам яктыртуын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу;

«РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Чишмә поселогының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова